# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге составына керүче Сүлә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

28.03.2024 №1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 28 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында» карарына таянып 2024 елның 28 мартында узган гражданнар җыенында «Сез «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге составына керүче Сүлә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 30.10.2023 ел №1 карарына үзгәрешләр кертүгә « 2024 нче елда Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге составына керүче Сүлә торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 (биш йөз ) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге максатларда файдаланырга:

1) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сүлә торак пунктында яр буе зоналарын чистарту?

2) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сүлә торак пунктында спорт мәйданчыкларын һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү?» дигән сорау буенча 2023 елның 30 октябрендә узган халык җыены 1 карарында күрсәтелгән эш төрләрен түбәндәге эш төрләренә үзгәртергә:

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (Сүлә торак пунктында яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту)

дигән сорау буенча 2024 елның 28 мартында узган халык җыены нәтиҗәләре буенча җыен беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 32 кеше кертелгән, җыенда һәм тавыш бирүдә катнашучылар саны 18 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 18 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге составына керүче Сүлә торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «Сез «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге составына керүче Сүлә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 30.10.2023 ел №1 карарына үзгәрешләр кертүгә, 30.10.2023 елгы 1 нче карарында күрсәтелгән эш төрләрен түбәндәге эш төрләренә үзгәртүгә:

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (Сүлә торак пунктында яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту)», карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/korsabash адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Курсабаш авыл җирлеге башлыгы

А.Р. Гыймадиев